ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 01 2023 г. № 42

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 февралендәге 52 номерлы карары белән расланган 16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 июлендәге 427 номерлы карары белән расланган, Түбән Кама муниципаль районы җирлеге территориясе өстендә авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын (максималь очып күтәрелү массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш), бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, шулай ук торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка утыртуга (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 февралендәге 79 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 6 июнендәге 346 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләрендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма укомитетының 2022 елның 28 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.4.1 пунктында «көннән» сүзеннән соң «, мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү датасыннан» сүзләрен өстәргә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов